| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 16.12.2016 г. Казань № 5-72/тэ

2017 елга «Энергошинсервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан бирелә торган җылы йортучегә тарифлар билгеләү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190 - ФЗ санлы Федераль законга, «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләр хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынучы бәяләрне (тарифларны) исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 2013 елның 13 июнендәге 760-э санлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2017 елга «Энергошинсервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан бирелә торган җылы йортучегә тарифларны әлеге карарның 1 кушымтасы нигезендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2017 елның 1 гыйнвареннән 2017 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 16.12.2015 № 5-72/тэ
карарына 1 кушымта

2017 елга календарь чорларына бүлеп «Энергошинсервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять тарафыннан бирелә торган җылы йортүчегә тарифлар

| № п/п | Көйләнүче оешманың атамасы | Тариф төре | Ел | Җылы йортүче төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | су | пар |
| | Кулланучыларга бирелүче җылы йортүчегә тарифлар | | | | |
| | Түбән Кама муниципаль районы | | | | |
| 1 | «Энергошинсервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять» | Бер ставкалы, сум./куб | 01.01.2017 алып 30.06.2017 кадәр | 20,05 | 65,47 |
| | | | 01.07.2017 алып 31.12.2017 кадәр | 20,80 | 67,01 |

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитетының тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештуры һәм җайга салу бүлеге